# Җиңүнең туган йөзләре

## *Миннеханов Галиәскәр Вадигулла улы (23.12.1923- 09.07.1993)*


Région 13 S/Secteur
Détach.
Nom Minikhanov
Prénoms Gali
Naissance Kazan
Matricule
Grade
Région
Bataillon
Compagnie
Date d'entrée dans les F.T.P.
Cachet
Le Cdt. de Compagnie :
Le
Signature :

Кулымда француз партизаны кенәгәсе. Андагы фотосурәттән миңа елмаеп татар егете карап тора. Андагы язмаларны укыйбыз: кенәгәнең иясе Миннеханов Гали, 1923 елның 23 декаберндә туган, Казаннан, француз партизаннарының 4Е батальонында, 16 нчы отрядта хезмәт итә. Кенәгә 1944 елның 30 августында тутырылган һәм имза, мөһер белән беркетелгән. Мөһердә “Франция республикасы” дип язылган.

Бәйрәкә егете Миннеханов Вадигулла улы Галиәскәр француз партизаннары сафына ничек барып кушылган соң? 1942 елның февралендә Миннеханов үзе теләп сугышка китә.
1942 елның августныда канкойгыч сугышлар вакытында дивизия һәм аның штабы чолганышта кала һәм Галиәскәр дивизиясе белән әсирлеккә эләгә. Франциянең бу төбәге 13 чне немец армиясе тарафыннан басып алынган була. Яңадан концлагерьләр, ай кебек сузылучы көннәр.
Әсирлектән котылырга аңа француз партизаннары ярдәм итә. . Шулай итеп Франция җирендә татар егетенең партизан тормышы башлана, Галиәскәр абыем француз партизаннары сафында 1 ел 4 ай буе сугыша. 1944 елның 6 июнендә каршы төндә союзникларның десантчылары Ла-Манш аша төньяк Франция ярына чыгалар, Америка армиясендә шофер булып та хезмәт итә, шуның өчен дә сугыш беткәч поселениягә җибәрелә, өйенә 1949 ел гына кайта. Гаилә корып, Урыссу поселогында ДОК комбинатында эшли, аннан соң Каразирек авылына урнаша. 1993 елны 70 яшендә үлә. Солдат үлгән, әмма француз партизаннары сафларында кулларына корал тотып сугышкан көрәшче даны яшь буын хәтерендә мәңге калыр.


Француз партизаннары


Миннеханов гаиләсе белән

***Сезнең буын нигез салган, саклап калган***
***Рәхәт илдә яшибез без җырлап кына.***
***Сезнең буын бу тормышны төзегән буын***
***Безнең көнгә куанып яши тыйнак кына!***